





Безнең адрес

Татарстан Республикасы Бөгелмә
шәһәре Совет урамы, 39 өй.

Телефон: 8 (85594) 6-63-96



***Горникова Ирина Ринатовна***

***төзеде***

**Татарстан Республикасы Бөгелмә
муниципаль районы мәктәпкәчә тәрбия
һәм белем бирү муниципаль бюджет
учреждениесе «Дельфин» 35нче гомум
үсеш төрендәге балалар бакчасы**

# *Туган илгә чиксез мәхәббәтем*

# *тел аша башлана*



***Татар теле – минем туган телем,***
***Сөйләшүе рәхәт ул телдә.***
***Шул тел белән көйлим...***
***Шул тел белән сөйлим***
***Милләттәшем булган һәркемгә.***
***Нәҗип Мадьяров***

**2014 ел.**

*Сандугачкай, сайра, сайра,*
*Котлап язгы таңнарны.*
*Туган җирдәй гүзәл җирләр*
*Дөньяда тагын бармы?*
*Резеда Вәлиева*

Балалар бакчасыннан башлап без балаларны халкыбызның гореф-гадәтлләре, йолалары, бәйрәмнәре, тарихы белән таныштырабыз. Тарихны өйрәнмичә, үткәнне белмичә, хәзерге тормышны аңлап, яңаны төзеп булмый. Чөнки бүгенге тормыш меңнәрчә елларның җимеше, нәтиҗәсе.



Мәктәпкәчә яштәге балалар шактый зур күләмле белемгә ия, аларда бүгенге көнгенә түгел, үткәннәр һәм киләчәктә кызыксыну уята. Алар олылар дөньясында булган хәлләр белән кызыксыналар. Балаларда туган якларына һәм аның тарихи үткәненә омтылу туа.



Зурлар төркемендәге балалар белән эшләгәндә, аларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып һәм дәүләт стандартларының “Балар тарих аркылы кеше турында мәгълүмәтләр бирү” дигән бүлегеннән чыгып, мин балаларны туган якның тарихы белән таныштыра башладым һәм үземнең алдымда шундый бурычлар куйдым.

1. Балаларда туган телгә, Туган илгә, аның табигатенә мәхәббәт тәрбияләү.
2. Туган илнең зурлыгына, табигать байлыгына соклану, кайгыртучанлык, сак караш тәрбияләү.
3. Туган илнең тарихи үткәненә кызыксыну, горурлык, патриотик һәм интернациональ хисләр тәрбияләү.
4. Туган якның күренекле кешеләре белән таныштыру.

Бу бурычларны күрсәтмә әсбаплар булган очракта гына тормышка ашырырга мөмкин. Шуңа күрә үз кабинетымда мин төрле күрсәтмәлекләр һәм “Борынгыдан киләчәккә” дигән кече музей оештырдым.

Татарстан Башкаласы буенча сәяхәт” альбомы ярдәмендә балаларны Казан Кремеле, Сөембикә, Спас манаралары белән таныштырдым.



Татар халкының борынгы бабалары-болгарлар, аларның гадәтләре, бәйрәмнәре белән танышу нәтиҗәсендә, балалар “Нәүрүз”, “Сабантуй” бәйрәмнәрендә катнашалар.

## *“Борынгыдан киләчәккә” кече музей.*











